Татарстан Республикасы Президенты Указы

**Татарстан Республикасының**
**инвестицион үсеш агентлыгы турында**

Татарстан Республикасына инвестицияләр җәлеп итү эшен камилләштерү, инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны комплекслы алып баруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитетын Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы итеп үзгәртеп оештыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдимен кабул итәргә.

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт-шәхси партнерлык, шәхси инвестицияләр, инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны комплекслы алып бару өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерүгә идарә итү функцияләрен һәм Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык мәсьәләләре буенча вәкаләтләр үтәүче махсус компетенцияле башкарма органы булып тора, дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитетының, шул исәптән төзелгән килешүләрдән һәм шартнамәләрдән килеп чыгучы йөкләмәләре буенча да, хокукый дәвамчысы булып тора, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитетын Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы итеп

үзгәртеп оештыру белән бәйле чаралар комплексын законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы арасында инвестиция эшчәнлеген үстерү өлкәсендәге вәкаләтләрне бүлешүне тәэмин итәргә һәм әлеге министрлыклар һәм аларның структуралары турындагы нигезләмәләргә тиешле үзгәрешләр кертергә;

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы турындагы Нигезләмәне эшләргә һәм расларга;

әлеге пунктның өченче абзацы нигезендә вәкаләтләр бүлешүне исәпкә алып, Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары санын билгеләү турында тәкъдимнәр кертергә;

әлеге пунктның өченче абзацы нигезендә вәкаләтләр бүлешүне исәпкә алып, Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы структурасын, хезмәткәрләренең иң чик санын расларга һәм аның эшчәнлеген финанслауга ассигнованиеләр күләмен 2011 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар чикләрендә билгеләргә;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә законнар нигезендә Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитетын Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы итеп үзгәртеп оештыру белән бәйле гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитетының Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы итеп үзгәртеп оештырылуы белән бәйле рәвештә тиешле закон проектларын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә;

үзенең актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты - Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2010 елның 22 апрелендәге ПУ-255 номерлы Указына «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты - Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлеге» кушымтасына (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 21 апрелендәге ПУ-231 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитеты рәисе» сүзләрен «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы турында» 2010 елның 22 апрелендәге ПУ-254 номерлы Указына (Татарстан Республикасы

Президентының 2010 елның 25 декабрендәге ПУ-863 номерлы һәм 2011 елның 5 мартындагы ПУ-108 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасының IV бүлегендә «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү комитеты турында» 2007 елның 31 декабрендәге ПУ-720 номерлы Указының 1–3 пунктларының үз көчен югалтуын танырга.

8. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2011 ел, 01 июнь
№ПУ-298